**«Татарча мемнар бәйгесе»нең нигезләмәсе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. «Татарча мемнар бәйгесе» – халыкның иҗади мөмкинлекләрен тормышка ашыруга юнәлтелгән медиапроект.

1.2. Бәйгенең максаты: яшьләр арасында татар телен популярлаштыру, аны көнкүрештә ешрак куллануга шартлар булдыру, кешеләрнең тормышка уңай карашын үстерү.

1.3. Бәйге үз алдына түбәндәге бурычларны куя:

- Татарстан тарихы һәм истәлекле урыннарына игътибар җәлеп итү.
- кешеләрнең ижади активлыгын куәтләү өчен шартлар тудыру;
- үз фикерләрен мемнар аша белдерүче яшьләрнең хезмәтләрен билгеләү һәм бүләкләү.

1.4. Гамәлгә куючы һәм оештыручы – «Ялкын» журналы («ТАТМЕДИА» АҖ филиалы – «Ялкын» журналы редакциясе).

## 2. Катнашучылар

2.1. Һәр кеше катнашучы була ала.

## 3. Бәйгенең үткәрү тәртибе

3.1. Конкурс эшләрен Ялкынның “Вконтакте”дагы берләшмәсенең хәбәрләренә (https://vk.com/yalkyn) яки yalkin@bk.ru электрон почтасына җибәрергә кирәк. Мемны документ итеп беркетергә һәм шунда ук исем, фамилия, яшь, шәһәр/авыл, тематика һәм телефон номерын язарга кирәк.

3.2. Җибәргәндә, тематиканы билгеләү мөһим.

* «Татарстанның 100-еллыгы». Бу бүлектә тарихи шәхесләр һәм вакыйгалар, Татарстан республикасының район һәм шәһәр үзенчәлекләре, татар халык ашлары, татар исемнәре һәм милләт сораулары чагылыш таба.

* «Җәмгыять һәм мин». Иҗтимагый проблемалардан тыш, җәмгыять өчен гадәти булган очраклар һәм сурәтләр. Темалар төрле: мәктәп-университет гадәтләре, хобби, спорт, мәдәният һәм көнкүреш.

* «Ялкын» журналы яндыра». Әлеге номинациядә укучылар үз иткән рубрикалар, мәкаләләр һәм тарихлар, яраткан авторлар, редакция һәм аның дуслары чагылыш таба.

* «Йолдызлы бум». Артистлардан башлап блогерларга кадәр медиа киңлегендә үзен күрсәткән шәхесләргә багышлана. Аларның аермалары һәм охшашлыклары. Нәрсә модада, ә нәрсә - юк?

* «Укымышлы мем». Мемнарны уку-укыту максатларында куллану өчен ясалган мемнар кабул ителә. Татар әдәбиятына бәйле мемнар көтелә.

3.3. Мемнарны документ белән jpg, png форматында җибәрү зарур.

3.4. Мемнарда кешеләрне түбәнсетә торган кимсетү һәм сүгенү сүзләрен куллану тыела.

3.5. Мемнар татар телендә генә кабул ителә. Алынма сүзләрне мөмкин кадәр азрак кулланырга тырышыгыз.

3.6. Катнашучыдан өчтән артык мем җибәрелергә тиеш түгел.

3.7. Конкурс эшләре редакция карары буенча “Ялкын” журналының рәсми сайтында (http://yalkyn.com) басылырга мөмкин.

## 4. **Бәйгене үткәрү вакыты**

4.1. Бәйге 10 гыйнвардан башлап 31 апрельгә кадәр үткәрелә.

4.2. Конкурс ике этапта үтә:

- 10 гыйнвардан 10 мартка кадәр конкурс эшләрен кабул итү;
- 10 марттан 31 апрельгә кадәр:

  - блогерлар белән түгәрәк өстәл вакытында иң яхшы мемнарны ачыклау;

- бүләкләү

4.3. Җиңүчеләрне бүләкләү датасы yalkyn.com сайтында язылачак.

## 5. Җиңүчеләрне бүләкләү

5.1. Җиңүчеләрне блогерлар, комиклар һәм ШТК командалары уенчыларыннан торган жюри билгели.

5.2. Конкурс эшенең критерийлары:

- креативлык;
- грамоталылык
- теманы ачып бирү.

5.3. Һәр катнашучыга электрон сертификат җибәрелә.

5.4. Һәр номинациядә өч призлы урын булачак. Җиңүчеләргә дипломнар һәм истәлекле бүләкләр тапшырыла. Блогерлар үз бүләкләрен билгеләргә мөмкин.

## 6. Оештыручыларның контактлары

6.1. «Ялкын» журналы редакциясе конкурс эшләрен рәсми сайтта, “Вконтакте” битендә урнаштыра һәм онлайн тавыш бирү оештыра ала. Тавыш бирү нәтиҗәләре исәпкә алынса да, әһәмияткә ия түгел.

6.2. Белешмәләр өчен телефон: 8(843) 222-06-01, 222-09-84 (1570, 1542).